МИНИСТЕРСТВО СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

30.03.2017 г.Казань № 66/2-пр

“2017 – 2020 елларга Татарстан Республикасында эш башлаучы фермерларга ярдәм” ведомство программасында катнашу өчен крестьян (фермер) хуҗалыкларын сайлап алу конкурсы турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Агросәнәгать комплексын үстерүнең региональ программаларының максат күрсәткечләренә ирешүгә ярдәм итү өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү турында” 2016 елның 30 декабрендәге 1556 номерлы карарын үтәү максатыннан һәм Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы белән Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең иң югары башкарма органы арасында төзелә торган 2017 елның 21 февралендәге 082-08-077 номерлы Россия Федерациясе субъекты бюджетына федераль бюджеттан субсидияләр бирү турында килешүгә нигезләнеп,

б о е р ы к б и р ә м:

1. Кушымта итеп бирелгән түбәндәгеләрне расларга:

1.1. “2017 – 2020 елларга Татарстан Республикасында эш башлаучы фермерларга ярдәм” ведомство программасын;

1.2. Крестьян (фермер) хуҗалыкларын үстерүгә конкурс үткәрү турында нигезләмәне расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының (алга таба – Министрлык) муниципаль районнардагы Авыл-хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләре башлыкларына “2017 – 2020 елларга Татарстан Республикасында эш башлаучы фермерларга ярдәм” программасында катнашу өчен крестьян (фермер) хуҗалыкларын мәгълүмат белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтергә.

3. Министрлыкның Финанс бүлеге башлыгы М.А. Мәхмүтовка Крестьян (фермер) хуҗалыкларын үстерүгә грантлар бирү турында нигезләмәдә каралган билгеләнгән лимитлар чикләрендә акчаларның үз вакытында алынуын тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының түбәндәге боерыкларын үз көчләрен югалткан дип таныргга:

“2015 – 2017 елларга Татарстан Республикасында эш башлаучы фермерларга ярдәм” ведомство программасын раслау турында” 2015 елның 17 мартындагы 50/2-пр номерлы;

“ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының “2015 – 2017 елларга Татарстан Республикасында эш башлаучы фермерларга ярдәм” ведомство программасын раслау турында” 2015 елның 17 мартындагы 50/2-пр номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында” 2015 елның 19 июнендәге 134/2-пр номерлы;

“ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының “2015 – 2017 елларга Татарстан Республикасында эш башлаучы фермерларга ярдәм” ведомство программасын раслау турында” 2015 елның 17 мартындагы 50/2-пр номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында” 2016 елның 26 гыйнварындагы 5/2-пр номерлы;

“ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының “2015 – 2017 елларга Татарстан Республикасында эш башлаучы фермерларга ярдәм” ведомство программасын раслау турында” 2015 елның 17 мартындагы 50/2-пр номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында” 2016 елның 13 апрелендәге 74/2-пр номерлы.

5. Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
урынбасары – министр М.Г.Әхмәтов

2017 елның ___ мартындагы
_______ 2-пр номерлы
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы боерыгы
белән расланды

# “2017 – 2020 ЕЛЛАРГА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА ЭШ БАШЛАУЧЫ ФЕРМЕРЛАРГА ЯРДӘМ”

ведомство программасы

Казан – 2017 ел

## Эчтәлек


| | | |
|---|---|---|
| | Паспорт | 3 |
| 1 бүлек | Программа белән хәл ителергә тиешле проблемаларга характеристика | 5 |
| 2 бүлек | Программаның максаты һәм бурычлары | 6 |
| 3 бүлек | Тормышка ашыруның нәтиҗәләре һәм максат индикаторлары | 6 |
| 4 бүлек | Программа гамәлләренең исемлеге һәм тормышка ашыру механизмы | 8 |
| 5 бүлек | Программаны тормышка ашыру сроклары | 14 |
| 6 бүлек | Программаны тормышка ашыруның социаль, икътисадый нәтиҗәләре тасвирламасы | 14 |
| 7 бүлек | Программаның нәтиҗәлелеген бәяләү һәм мониторинг ясау | 15 |
| 8 бүлек | Кирәкле ресурсларга ихтыяҗны исәпләп чыгару | 16 |
| 9 бүлек | Программаны тормышка ашыру белән идарә игү системасы | 16 |

1 нче кушымта

2 нче кушымта

**ПАСПОРТ**

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | “2017 – 2020 елларга Татарстан Республикасында эш башлаучы фермерларга ярдәм” ведомство программасы (алга таба – Программа) |
| Программаны эшләү турында карар кабул ителгән дата (аны раслау датасы, тиешле норматив актнын исеме һәм номеры) | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “2013 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу” дәүләт программасын раслау турында” 2013 елның 8 апрелендәге 235 номерлы карары |
| Дәүләт заказчысы – Программаның координаторы | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы (алга таба – Министрлык) |
| Программаны төп эшләүчеләр | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы |
| Программаның максаты һәм бурычлары | Программаның максаты:<br>авыл халкының яшәү шартларын яхшырту,<br>шәһәр һәм авыл халкын үзебездә житештерелгән авыл хуҗалыгы продукциясе белән тәэмин итү |
| Программа гамәлләренә характеристика | Бурычларны тормышка ашыруга юнәлдерелгән гамәлләр комплексы түбәндәге юнәлешләрне үз эченә ала:<br>крестьян (фермер) хужалыгын төзүгә һәм үстерүгә грантлар бирү;<br>эш башлаучы фермерларны көнкүреш кирәк-яраклары белән тәэмин итүгә бер тапкыр ярдәм күрсәтү;<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 8 апрелендәге 235 номерлы карары белән расланган “2013 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал, азык-төлек базарларын җайга салу” дәүләт программасында каралган чараларда катнашу |
| Прогорамманы тормышка ашыру сроклары | 2017 ел – 70 КФХ төзү, 140 эш урыны булдыру;<br>2018 ел – 70 КФХ төзү, 140 эш урыны булдыру;<br>2017 ел – 70 КФХ төзү, 140 эш урыны булдыру;<br>2020 ел – 70 КФХ төзү, 140 эш урыны булдыру. |

| | |
|---|---|
| Финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | 2017-2020 елларга Программаны финанслауның гомуми күләме 621 млн.сум тәшкил итә:<br>шул исәптән еллар буенча:<br>2017 ел – 155,6 млн. сум;<br>2018 ел – 155,6 млн. сум;<br>2019 ел – 155,6 млн. сум;<br>2020 ел – 155,6 млн. сум.<br>Федераль бюджеттан финанслау – барлыгы 400 млн. сум, шулардан:<br>2017 ел – 100 млн. сум;<br>2018 ел – 100 млн. сум;<br>2019 ел – 100 млн. сум;<br>2020 ел – 100 млн. сум.<br>Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслау – 160 млн. сум, шулардан:<br>2017 ел – 40 млн. сум;<br>2018 ел – 40 млн. сум;<br>2019 ел – 40 млн. сум;<br>2020 ел – 40 млн. сум.<br>Җәлеп ителгән акчалар, барлыгы – 61,6 млн. сум, шулардан:<br>2017 ел – 15,6 млн. сум;<br>2018 ел – 15,6 млн. сум;<br>2019 ел – 15,6 млн. сум;<br>2020 ел – 15,6 млн. сум. |
| Программа гамәлләрен тормышка ашырудан көтелә торган ахыргы нәтиҗәләр һәм социаль-икътисадый нәтиҗәлелек күрсәткечләре | Үзләренең крестьян (фермер) хуҗалыкларын үстерү проектларын дәүләт ярдәме белән тормышка ашырган крестьян (фермер) хуҗалыклары саны – 280 берәмлек,<br>шул исәптән:<br>2017 елда – 70 берәмлек;<br>2018 елда – 70 берәмлек;<br>2019 елда – 70 берәмлек;<br>2020 елда - 70 берәмлек.<br>4 елда булдырылган эш урыннары саны – кимендә 560 |

## Программаның төп төшенчәләре

**Эш башлаучы фермер** – теркәлү датасыннан иң күбе 24 ай эшләүче крестьян (фермер) хуҗалыгын үстерүгә грант бирү өчен крестьян (фермер) хуҗалыкларын сайлап алу буенча конкурс комиссиясе тарафыннан билгеләнгән эш башлаучы фермерларга Ярдәм программасында катнашучы (алга таба – КФХ).

**Крестьян (фермер) хуҗалыгын төзүгә һәм үстерүгә грант** – Татарстан Республикасы авыл җирлекләре территориясендә һәм авылара территорияләрдә КФХ төзү һәм үстерү максатларында Программа нигезендә дәүләт ярдәменең башка

юнәлешләре кысаларында капланмый торган түбәндәгеләр буенча чыгымнарны финанслашу өчен КФХ башлыгы хосусый счетына федераль бюджеттан, Татарстан Республикасы бюджетыннан күчерелә торган акчалар:

авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән җир кишәрлекләрен сатып алу;

авыл хуҗалыгы терлекләрен асрау, авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү, саклау һәм эшкәртү өчен кирәк булган җитештерү һәм саклау биналарын, урыннарын төзү (реконструкцияләү) өчен проект документларын эшләү;

авыл хуҗалыгы терлекләрен асрау, авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү, саклау һәм эшкәртү өчен кирәк булган җитештерү һәм саклау биналарын, урыннарын, өстәмә корылмаларны, инженер челтәрләрен, киртәләрне һәм корылмаларны сатып алу, төзү, ремонтлау һәм янадан төзү, шулай ук аларны теркәү;

авыл хуҗалыгы терлекләрен асрау, авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү, саклау һәм эшкәртү өчен кирәк булган җитештерү һәм саклау өбъектларына алып килә торган юлларны һәм керү юлларын төзү;

авыл хуҗалыгы терлекләрен асрау, авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү, саклау һәм эшкәртү өчен кирәк булган җитештерү һәм саклау биналарын, урыннарын, өстәмә корылмаларны һәм төзелмәләрне инженер челтәрләренә - электр, су, газ һәм җылылык челтәрләренә, юл инфраструктурасына тоташтыру;

авыл хуҗалыгы терлеген сатып алу;

авыл хуҗалыгы техникасын һәм инвентарен, йөк автомобиле транспортын, авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү һәм эшкәртү өчен җиһазлар сатып алу;

күпьеллык үсемлекләр утырту өчен орлыклар һәм утырту материалларын сатып алу;

ашлама һәм агулы химикатлар сатып алу.

## I. Программа белән хәл ителергә тиешле проблемаларга характеристика

Соңгы елларда турыдан-туры агросәнәгать комплексы оешмаларында эшләүче авыл халкы саны туктаусыз кими һәм 80 меңнән кимрәк кешене тәшкил итә. Шул рәвешчә аларны эшкә урнаштыру, эш белән тәэмин итү, керемнәр белән тәэмин итү мәсьәләсе килеп туа, аны хәл итүгә республикада бер-берсенә бәйле чараларның тулы бер комплексы эшләнгән. Программа авыл җирлегендә яшәүчеләрнең тормыш дәрәҗәсен күтәрергә, авылда яшьләрнең эшлекле активлыгын күтәрергә, авылча яшәү рәвешен саклап калуга юнәлдерелгән.

Авылда кадрлар составын ныгыту, кече бизнесны үстерү һәм яңа эш урыннары булдыру, авыл яшьләренең кызыксынуын һәм эш белән тәэмин ителешен арттыру максатларында программа белән КФХ үстерү буенча гамәлләр комплексы тәкъдим ителә. Эш башлаучы КФХ җитди мәсьәләләр белән очраша: башлангыч капитал җитмәве сизелә, закладка куя торган мөлкәт җитмәү сәбәпле, алар кредитлар ала алмыйлар. Соңгы елларда көнкүреш кирәк-яраклары белән тәэмин ителү мәсьәләсе кискен тора, бу үз чиратында өстәмә акчалар таләп итә. Крестьян (фермер) хуҗалыклары, финанс тотрыклылыгына ирешә алмыйча, үз эшчәнлекләрен туктаталар.

Моның белән бергә халыкның шәхси ярдәмче хуҗалыклар секторында ике һәм аннан күбрәк гектар җир үз милкендә яки файдалануында булган һәм товар продукция җитештерүгә юнәлдерелгән хуҗалыклар барлыкка килде. Инде хәзер үк алар продукция күләме белән кайбер фермер хуҗалыкларын узып китәләр. Чынлыкта исә билгесез статуслы, торгызу элемтәләре бозылган габигый крестьян хуҗалыклары барлыкка килә. Мондый хуҗалыкларның формалашуы эре күмәк предприятиеләр таркалганда аларның хуҗаларының киләчәктә гамәлдә булуларын сайлау альтернативасы булмау белән аңлатыла.

Соңгы елларда авыл хуҗалыгы оешмаларын үстерү тәҗрибәсе күрсәткәнчә, хуҗалык эшчәнлегендә ирешелгән нәтиҗәләр крестьяннарның социаль проблемаларын үз көчләре һәм чаралары белән генә нәтиҗәле хәл итәргә һәм җитештерүне яңартуга мөмкинлек бирмиләр.

Яңа КФХ төзү шулай ук хуҗалык корылмаларын проектлау, аларны инженер челтәрләренә тоташтыру, лизинг түләүләре буенча беренче кертемне түләү өчен шактый күп чыгымнар таләп итә.

Авылда хуҗалык итүнең кече рәвешләренә ярдәм итү буенча алып барыла торган дәүләт сәясәте кече авыл хуҗалыгы эшкуарлыгы субъектларына банкларының субсидияләнә торган кредитларын һәм авыл хуҗалыгы кулланучылары кооперативларының субсидияләнә торган заемнарын алу мөмкинлеген киңәйтә алды.

Хуҗалык итүнең кече рәвешләренә ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан дәүләт ярдәме күләме 2006 елдан җәлеп ителгән инвестицияләнгән һәм кыска вакытлы кредитлар һәм заемнар буенча процент ставкаларын субсидияләү рәвешендә 37,8 млрд. сум тәшкил итә.

Статистика мәгълүматлары буенча 2017 елның 1 гыйнварына КФХ гомуми саны 5083 берәмлек тәшкил итә.

Үсешнең сценариясе сүлпән булган очракта фермер секторы үз үсешен алга җибәрү өчен өстәмә чыганак таба алмаячак, ә ярлыланган эчке чыганаклар авыл хуҗалыгының җитештерү вазыйфасын тәэмин итә алмаячак.

## II. Программаның максаты һәм бурычы

Программаның максаты – авыл халкының яшәү шартларын яхшырту, шәһәр һәм авыл халкын үзебездә җитештерелгән авыл хуҗалыгы продукциясе белән тәэмин итү.

Әлеге максатны тормышка ашыру һәм җитештерү балансының, шулай ук авыл хуҗалыгы продукциясен куллануның тотрыклылыгы кысаларында дәүләт ярдәме түбәндәге юнәлешләрдә гамәлгә ашырылачак:

сөт терлекчелеге;

мөгезле эре терлекне симертү;

атчылык;

сарык үрчетү;

кәҗә үрчетү;

дуңгызчылык;

авыл хуҗалыгы кошчылыгы;

бөртекле һәм бөртекле-кузаклы культуралар, азык культуралары житештерү;

бәрәңге үстерү;

яшелчәчелек (ачык һәм ябык грунтта);

җимеш һәм җиләк культуралары үстерү.

Программаның бурычы – крестьян (фермер) хуҗалыгын төзү һәм үстерү нигезендә авыл хуҗалыгы продукциясен житештерүне арттыру;

гражданнарны, шул исәптән шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару белән шөгыльләнүче гражданнарны, крестьян (фермер) хуҗалыкларын (алга таба – КФХ) төзүгә кызыксындыру.

## III. Тормышка ашыруның нәтиҗәләре һәм максат индикаторлары

3. Программа гамәлләрен тормышка ашырудан көтелә торган ахыргы нәтиҗәләр һәм социаль-икътисадый нәтиҗәлелек күрсәткечләре

Эш башлаучы фермерлар үзләренең КФХ үстерү проектларын дәүләт ярдәменнән файдаланып гамәлгә ашыра алачаклар.

3.1. Программа чараларын тормышка ашыру түбәндәге нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирә:

3.1.1. Кимендә 560 өстәмә эш урыны булдыру, бу исә авыл җирлекләре территорияләрен ныклы үстерергә һәм үзләштерергә, шулай ук авыл җирлегендәге урнашу системасын саклап калырга мөмкинлек бирә;

3.1.2. КФХ төзүгә һәм үстерүгә һәм авыл җирлегендә гадәти тормыш рәвешен саклап калуга ярдәм алу.

3.2. Программа чараларын тормышка ашыруның максат индикаторлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

үз хуҗалыкларын үстерү проектларын дәүләт ярдәменнән файдаланып тормышка ашырган КФХ саны;

булдырылган өстәмә эш урыннары саны.

**1таблица**

**Максат индекаторлары**

| Күрсәткечләр | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2017-2020 елларда барлыгы |
|---|---|---|---|---|---|
| Үз хуҗалыкларын үстерү проектларын дәүләт ярдәменнән файдаланып тормышка ашырган КФХ саны | 70 | 70 | 70 | 70 | 280 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Булдырылган өстәмә эш урыннары саны | 140 | 140 | 140 | 140 | 560 |

Программа чараларын тормышка ашыруның нәтиҗәсе объективлык, дөреслек, ачыклык, нисбәт критериеләренә җавап бирә торган күләмле күрсәткечләр белән билгеләнәләр.

**2 таблица**

**Программаның нәтиҗәсе**

| Максат индикаторы | Көтелә торган дәрәҗә | 2017 елның 1 гыйнварына (Росстат күрсәткечләре) | Индикатор күрсәткече, берәмлек | | | | Максатка ирешү елы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | |
| **Фермерлар саны** | 5363 | 5083 | 5153 | 5223 | 5293 | 5363 | 2020 |
| шул исәптән үз КФХ үстерү проектларын дәүләт ярдәменнән файдаланып тормышка ашырганнар | 280 | Х | 70 | 70 | 70 | 70 | |

Индикатор күрсәткече – хуҗалык алып баручы КФХ санының 2017 ел дәрәҗәсенә карата артуы.

Максат индикаторын исәпләп чыгару түбәндәге формула буенча башкарылды:

$$K = \frac{S}{S_Z}.$$

монда:

К – максат индикаторы;

S – 2020 елның 1 гыйнварына хуҗалык итүче КФХ саны;

$S_Z$ – 2017 елның 1 гыйнварына хуҗалык итүче КФХ саны.

Программа чараларын тормышка ашыру ахырына максат индикаторы күрсәткече түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$K = \frac{5363}{5083} = 1{,}05$$

## IV. Программа гамәлләренең исемлеге һәм тормышка ашыру механизмы

4.1.1. КФХ төзү һәм үстерү өчен эш башлаучы КФХ башлыкларына грантлар бирү Программаның төп гамәлләре булып торалар.

4.1.2. Эш башлаучы фермерларга ярдәм итү буенча Программага комплекслы ярдәм күрсәтүне тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетынын "2013-2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал, азык-төлек базарларын җайга салу" дәүләт программасын (алга таба – Дәүләт программасы) раслау турында" 2013 елның 8 апрелендәге 235 номерлы карары белән расланган "2013-2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал, азык-төлек базарларын җайга салу" дәүләт программасы (алга таба – Дәүләт программасы) кысаларында түбәндәге гамәлләр карала:

банкларны озак вакытка һәм кыска вакытка ташламалы кредитлау;

эш башлаучы фермерлар җитештерә торган авыл хуҗалыгы продукциясен сатуны оештыру.

4.1.3. Авыл хуҗалыгы техникасына, җиһазларына лизинг буенча кертемнең бер өлешен каплау. Чара "Кече һәм урта эшкуарлыкка, крестьян (фермер) хуҗалыкларын да кертеп, дәүләт ярдәме максатларында Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү турында" 2014 елның 30 декабрендәге 1605 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәтекарары кысаларында җиһазларны лизингка алу шартнамәләре буенча беренче түләүләрне түләүгә максатчан субсидиеләр бирүне үз эченә ала;

4.1.4. Эш башлаучы фермерлар тарафыннан җәлеп ителгән кредитлар һәм заемнар буенча эшкуарлыкка ярдәм итү фондларыннан йөкләмәләр һәм гарантияләр бирү ("Татарстан Республикасының Гарантияләр фонды" коммерциягә карамаган берләшмәсе");

4.1.5. Эш башлаучы фермерларның производство һәм социаль объектларына инженер-техник инфраструктураны төзү һәм ремонтлау "2013-2020 елларга авыл территорияләрен тотрыклы үстерү" ярдәмче программасы кысаларында тормышка ашырыла;

4.1.6. Эш башлаучы фермер хуҗалыкларын үстерүгә теләктәшлек күрсәтү өчен, торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлык булганда, КФХ башлыклары "2013 - 2020 елларга авыл территорияләрен тотрыклы үстерү" ярдәмче программасы кысаларында гамәлгә ашырыла торган торак шартларын яхшырту буенча программаларга кертелә алалар;

4.1.7. КФХ төзергә теләүче гражданнарга Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында (алга таба – Министрлык) һәм Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районнарындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләрендә (алга таба – Идарәләр) белгечләр тарафыннан консультация хезмәтләре күрсәтү.

Министрлык түбәндәгеләрне тәэмин итә:

эш башлаучы фермерларга ярдәм программасын уздыру һәм анда катнашу тәртибе турында мәгълүматтан гражданнарның законнар нигезендә ирекле файдалана алуын;

эш башлаучы фермерларның авыл хуҗалыгын үстерү буенча Дәүләт программасы һәм региональ программалар гамәлләрендә, агробизнес өлкәсендә катнашуын.

Җирләрнең булуы турында белешмәләр һәркем өчен ачык була.

Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы республика гаризасы һәм төзелгән Килешүләр нигезендә Дәүләт программасы кысаларында һәм шартларында Программа чараларын финанслашуда катнаша. Финанслашу “Агросәнәгать комплексын үстерүнең региональ программалары максат күрсәткечләренә ирешүгә ярдәм итү өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү турында” 2016 елның 30 декабрендәге 1556 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән билгеләнгән шартларга ярашлы рәвештә һәм лимитлар кысаларында башкарыла.

4.2. Эш башлаучы фермерларны сайлап алу буенча конкурс үткәрү тәртибен һәм гариза бирүчеләрне эш башлаучы фермерларга булышу буенча ведомство программасы составына кертү турында карар кабул итү тәртибен үз эченә алган крестьян (фермер) хуҗалыкларын төзүгә һәм үстерүгә грантлар бирү турында нигезләмә. Министрлык Программа катнашучыларын сайлап алуга конкурс игълан итә, аны үткәрү тәртибен һәм вакытын билгели.

Конкурс комиссиясе составына республиканың дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләре (комиссия составының кимендә 50%), агросәнәгать комплексы тармагында эшчәнлек алып баручы юридик һәм физик затлар кертелә. Конкурс комиссиясе составына кредит, фәнни, мәгариф, юридик, консультация, консалтинг, аудит, ревизия һәм җәмәгатьчелек оешмалары, фермерлар ассоциацияләре вәкилләре кертелергә мөмкин.

Конкур комиссиясе гариза бирүчеләрнең заявкаларын (алга таба – Заявка) һәм аларга кагылышлы документларны Министрлык боерыгы белән билгеләнгән срокларда карап тикшерә, гариза бирүче белән кара-каршы әңгәмә үткәрә, аны Программада катнашучылар составына кертә, КФХ төзүгә һәм үстерүгә грант суммаларын билгели.

Конкурска документларын тапшырганда гариза бирүче Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча Заявка һәм аңа теркәлә торган документларның исемлеген һәр як өчен бер нөсхә исәбеннән ике нөсхәдә төзи.

Конкурс комиссиясе, гариза бирүчеләрне Программада катнашучылар составына кертү турында карар кабул иткәндә, гариза бирүченең документларында күрсәтелгән мәгълүмат белән бергә түбәндәгеләрне исәпкә ала:

гариза бирүченең яшәү шартларын;

җитештерелә торган авыл хуҗалыгы продукциясен сатуның үз каналлары булу-булмауны;

авыл хуҗалыгы кулланучылары кооперативларында әгъзалыкны;

җирле халык өчен эш урыннары бирелүен;

социаль һәм бюджет җаваплылыгын;

производство фондлары булуны;

нәселле авыл хуҗалыгы терлеге булуны;

авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр булуын;

эшчәнлек репутациясен һәм кредит тарихын;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең жирле үзидарә органнарыннан, физик затлардан, жәмәгатьчелек оешмаларыннан, йөкләмләрне үз өстенә алучылардан тәкъдимнәрне һәм мөрәжәгатьләрне,

кара-каршы әңгәмә нәтижәләрен.

Эш башлаучы фермерга ведомство Программасында катнашуы турында 1 нче кушымта нигезендә саклагыч дизайны һәм билгесе булган сертификат бирелә.

4.3. КФХ төзүгә һәм үстерүгә грант – Министрлык тарафыннан түбәндәгечә күчерелә торган бюджет акчалары ул:

ЕГРЮЛ реестрында теркәлгән эш башлаучы фермерның Федераль казначылык органының Татарстан Республикасы буенча территориаль бүлегендә ачылган хосусый счетына;

ЕГРИП реестрында теркәлгән эш башлаучы фермерның Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яки кредит оешмаларында ачылган хосусый счетына

Татарстан Республикасы авыл жирлекләре территориясендә һәм авылара территорияләрдә КФХ төзү һәм үстерү максатларында Программа нигезендә дәүләт ярдәменең бүтән юнәлешләре кысаларында кайтарылмый торган чыгымнарын финанслашу өчен.

Крестьян (фермер) хужалыгын төзүгә һәм үстерүгә грантның иң зур күләме Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “2017 елда агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында” 2017 елның 10 февралендәге 77 номерлы карары белән расланды.

Эш башлаучы фермерга бирелә торган КФХ төзүгә һәм үстерүгә грантның суммасы эш башлаучы фермерның үз акчалары барлыгын исәпкә алып, конкурс комиссиясе тарафыннан билгеләнә. Грант суммасы эш башлаучы фермерның чыгымнары планына төгәл туры килергә тиеш. Эш башлаучы фермер тарафыннан чыгымнар планын үзгәртү, шул исәптән бирелгән грант кысаларында. конкурс комиссиясе белән килештерелергә тиеш.

Чыгымнар планына Татарстан Республикасы территориясендә КФХ үстерүгә каралган һәм түбәндәге максатларга туры килә торган исемнәр (статьялар) кисемендәге чыгымнар керә:

авыл хужалыгы билгеләнешендәге жирләрдән жир кишәрлекләрен сатып алу;

авыл хужалыгы терлекләрен асрау, авыл хужалыгы продукциясен житештерү, саклау һәм эшкәртү өчен кирәк булган житештерү һәм саклау биналарын, урыннарын төзү (реконструкцияләү) өчен проект документларын эшләү;

авыл хужалыгы терлекләрен асрау, авыл хужалыгы продукциясен житештерү, саклау һәм эшкәртү өчен кирәк булган житештерү һәм саклау биналарын, урыннарын, өстәмә корылмаларны, инженер челтәрләрен, киртәләрне һәм корылмаларны сатып алу, төзү, ремонтлау һәм яңадан төзү, шулай ук аларны теркәү;

авыл хужалыгы терлекләрен асрау, авыл хужалыгы продукциясен житештерү, саклау һәм эшкәртү өчен кирәк булган житештерү һәм саклау объектларына алып килә торган юлларны һәм керү юлларын төзү;

авыл хуҗалыгы терлекләрен асрау, авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү, саклау һәм эшкәртү өчен кирәк булган җитештерү һәм саклау биналарын, урыннарын, остәмә корылмаларны һәм төзелмәләрне инженер челтәрләренә - электр, су, газ һәм җылылык челтәрләренә, юл инфраструктурасына тоташтыру;

авыл хуҗалыгы терлеген сатып алу;

авыл хуҗалыгы техникасын һәм инвентарен, йөк автомобиле транспортын, авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү һәм эшкәртү өчен җиһазлар сатып алу;

күпьеллык үсемлекләр утырту өчен орлыклар һәм утырту материалларын сатып алу;

ашлама һәм агулы химикатлар сатып алу.

Чыгымнар планы буенча чыгым эш башлаучы фермер чараларының һәр исеме (статьясы) буенча түбәндәгечә гамәлгә ашырыла: иң күбе 90 проценты - грант акчалары хисабына һәм кимендә 10 проценты - эш башлаучы фермерның җәлеп ителгән акчалары хисабына.

Грант хисабына алынган барлык активлар[1] эш башлаучы фермер исеменә теркәлергә һәм аның Татарстан Республикасы территориясендәге КФХ белән һәм бары тик эш башлаучы фермерның КФХ эшчәнлегендә генә кулланылырга[2] тиеш.

КФХ төзүгә һәм үстерүгә грант максатчан файдаланылмаган очракта, грантның максатчан файдаланылмаган суммасы законнар нигезендә тиешле бюджетларга кире кайтарылырга тиеш.

Эш башлаучы фермер тарафыннан грант хисабына сатып алынган мөлкәт грант алган көннән соң 10 ел эчендә Россия Федерациясе законнары нигезендә сатылырга, бүләк ителергә, арендага, башка затларга куллануга тапшырылырга, алыштырылырга яки пай, кертем рәвешендә кертелергә яки бүтән рәвештә таргып алынырга тиеш түгел. Әлеге шарт эш башлаучы фермерларга грантлар бирү буенча чараларда катнашучылар өчен мөһим булып тора һәм ул Министрлык белән эш башлаучы фермер арасында төзелгән килешүләрдә күрсәтелергә тиеш.

КФХ төзүгә һәм үстерүгә грант КФХ башлыгына бер генә тапкыр бирелә. КФХ башлыгы кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм итү өчен каралган Дәүләт программаларының программа гамәлләре исемлегенә кертелергә мөмкин.

4.4. Министрлык эш башлаучы фермерлар тарафынан акчаларның хәрәкәтенә һәм максатчан тотылышына контрольне тәэмин итә.

Грантны һәм (яки) ярдәмне максатчан файдаланмау һәм (яки) аларны алу өчен дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшыру фактлары билгеле булган очракта, бирелгән грантлар Министрлыктан тиешле таләп алынган датадан соң алтмыш кон эчендә Татарстан Республикасы бюджеты һәм Россия Федерациясе бюджеты кереме булып кире кайтарылырга тиеш.

Акчаларны максатчан тоту өчен җаваплылык эш башлаучы фермерларга йөкләнә.

---

[1] Активлар Татарстан Республикасыннан читтә сатып алынырга мөмкин, әмма аның территориясенә кертелергә тиеш.
[2] Транспорт чаралары эш башлаучы фермерлар тарафыннан Татарстан Республикасыннан читтә чикләүсез файдаланырга мөмкин, әмма Татарстан Республикасы территориясендә теркәлергә тиеш.

4.6. Эш башлаучы фермер елына ике тапкыр Министрлыкка КФХ төзү һәм үстерү өчен грант суммасын максатчан тоту турында Министрлык билгеләгән форма буенча хисап һәм 2-фермер, 3-фермер статистик хисабын тапшыра. КФХ төзү һәм үстерү өчен грант суммалары объектларны төзүгә (реконструкцияләүгә) тотылганда, эш башлаучы фермер төзелеш тогәлләнү факты хакында шулай ук 2-КС һәм 3-КС формалары буенча хисап тота.

Бирелә торган хисапларның дөреслеге өчен җаваплылык эш башлаучы фермерларга йөкләнә. Хисаплар грант һәм (яки) ярдәм алган көннән 5 ел дәвамында тапшырыла.

Бирелә торган хисапларның дөреслеген тикшереп торуны Министрлык башкара.

## V. Программаны тормышка ашыру сроклары

Программа 2017–2020 еллар вакыт аралыгында тормышка ашырыла.

## VI. Программаны тормышка ашыруның социаль, икътисадый нәтиҗәләре тасвирламасы

### 6.1. Максатка ирешүдә Программа керткән өлешкә гомуми бәя

Программа гамәлләрен тормышка ашыру авыл хуҗалыгы өлкәсендә түбәндәге стратегик максатларга ирешүгә ярдәм итәчәк:

авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү һәм сату күләмнәрен арттыруга һәм аның конкурентлык сәләтен көчәйтүгә, авыл халкының эш белән тәэмин ителешен һәм яшәү дәрәҗәсен үстерүгә, авыл җирлеге территорияләренең тотрыклы үстерүгә;

авыл халкының эшлекле активлыгын көчәйтүгә, эшкуарлык эшчәнлеге белән кызыксынуны арттыруга.

Программа гамәлләрен тормышка ашыру авылда хуҗалык итүнең кече формаларын тотрыклы үстерүгә һәм аларга дәүләт ярдәме механизмнарын оптимальләштерүгә алшартлар тудырачак.

### 6.2. Программа гамәлләрен тормышка ашыруның социаль һәм икътисадый нәтиҗәләре

Программаның максат күрсәткечләрендә каралганча, үз хуҗалыкларын төзү һәм үстерү проектларын гамәлгә ашыручы крестьян (фермер) хуҗалыклары саны 280 берәмлек тәшкил итә. Программа чараларын гамәлгә ашыру кимендә 560 өстәмә эш урыны булдыруны тәэмин итәчәк.

Нәтиҗәдә дәүләт федераль бюджеттан һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан эшсезлек буенча пособиегә түләүләр күләме кимүдән һәм салым җыемнары артудан өстәмә икътисадый файда алачак.

Программа гамәлләрен тормышка ашыру тискәре экологик нәтиҗәләргә китерми, әмма авыл хуҗалыгы җирләренең сыйфатын яхшырту буенча культура-

техника чаралары юлы белән табигый ресурсларның сакланып калуына ярдәм итәчәк.

Программаның гамәлдә ирешелгән нәтиҗәләре беренчел планлаштырылганнарыннан үзгә булуына тәэсир итәргә мөмкин тышкы шартларга һәм куркынычларга түбәндәгеләр керә:

финанслауның начар булуы, ул крестьян (фермер) хуҗалыкларының һәм терлекчелек продукциясен беренчел эшкәртү цехларынын физик таушалган һәм вакыт ягыннан искергән техник базасын яңартырга, шулай ук авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр мәйданын киңәйтергә мөмкинлек бирмәячәк;

ягулык-майлау материалларына, авыл хуҗалыгы техникасына һәм җиһазларына, минераль ашламаларга һәм пестицидларга, терлекчелек фермаларын төзү өчен материалларга бәянең күтәлгәннән инфляция темплары аркасында артык үсүе;

аномаль һава торышы шартлары һәм административ реформа белән, шулай ук федераль башкарма хакимият органнары структурасы үзгәрү һәм Россия Федерациясе белән Татарстан Республикасы арасындагы тиешле вәкаләтләрне яңадан бүлешү белән бәйле мөмкин булган институциональ үзгәртеп корулар аркасында килеп туарга мөмкин форс-мажор вакыйгалар.

Күрсәтелгән куркынычлар форс-мажор булып торалар яки Министрлык системасына керми торган хакимият органнары эшчәнлегенә бәйле булалар, шуңа күрә әлеге куркынычларны алдан күреп булмый.

## VII. Программаның нәтиҗәлелеген бәяләү һәм мониторинглау.

Программа гамәлләрен тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү, ел саен Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы Президенты һәм Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы арасында ел саен төзелә торган килешүдә билгеләнгән нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешү дәрәҗәсеннән чыгып, Татарстан Республикасында хуҗалык итүче КФХ саны артуның килешүдә билгеләнгән зурлыкларга туры килүе нигезендә гамәлгә ашырыла.

Республикада әлеге Программа кысаларында 2017 – 2020 еллар чорында төзелгән КФХ санын 165 фермерга арттыру планлаштырыла, алар сайлап алу нигезендә дәүләт ярдәме катнашында үзләренең КФХ үстерү проектларын гамәлгә ашыра алачаклар.

Министрлык түбәндәгеләрне тапшыра:

Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгына – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан билгеләнгән хисап формасы буенча Татарстан Республикасы Президенты һәм Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы арасындагы эш башлаучы фермерларга ярдәм итү буенча килешүдә беркетелгән күрсәткечнең үтәлеше турында мәгълүматны;

квартал саен, хисап чорыннан соң килүче айның 25 числосына кадәр, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы дәүләт программаларын эшләү,

тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен һәм Татарстан Республикасы дәүләт программалары исемлеген раслау турында” 2012 елның 31 декабрендәге 1199 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибенең 2 нче кушымтасында бирелгән форманы тутыру юлы белән максатчан программаларны әзерләү һәм тормышка ашыру турында статистик, белешмә һәм аналитик мәгълүматны;

ел саен, хисап чорыннан соң килүче елның 1 мартына кадәр, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына – программаларны тормышка ашыру буенча эшләрнең барышы һәм финанс чараларын тотуның нәтиҗәлелеге турында мәгълүматны билгеләнгән тәртип нигезендә докладлар составында.

## VIII. Кирәкле ресурсларга ихтыяҗны исәпләп чыгару

Программаны финанслау агымдагы елга һәм план чорына федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты турында ел саен кабул ителә торган законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

Программада каралган барлык гамәлләрне финанслау еллар буенча беркадәр дифференциацияләү белән, аларның кирәклеген, шулай ук нәтиҗәләр һәм алдагы елда гамәлләрне тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләүне исәпкә алып, Программаны тормышка ашыруның барлык срогы дәвамында гамәлгә ашырыла.

Эш башлаучы фермерларга КФХ үстерү өчен грантларның гомуми суммасы 2017 – 2020 елларга 621 млн. сум тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджетыннан 160 млн. сум.

**3 нче таблица**

**Программа чараларын финанслау күләмнәре**

(млн.сум)

| Финанслау чыганаклары | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2017–2020 еллар |
|---|---|---|---|---|---|
| Финанслауның гомуми күләме – барлыгы, шул исәптән: | 140,0 | 140,0 | 140,0 | 140,0 | 560,0 |
| федераль бюджет | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 400,0 |
| Татарстан Республикасы бюджеты | 40,0 | 40,0 | 40,0 | 40,0 | 160,0 |
| җәлеп ителгән акчалар | 15,6 | 15,6 | 15,6 | 15,6 | 62,4 |

Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләр бюджетларына акчалар жирле үзидарә органнары карары буенча җәлеп ителергә мөмкин.

Бюджеттан тыш чыганаклар:

1) коммерциягә караган банкларның акчалары – банклар тарафыннан кече һәм урта эшкуарлык субъектларын кредитлау өчен каралган кредит ресурслары;

2) бюджеттан тыш чыганаклардан финанслана торган оешмалар арасыннан булган катнашучыларның акчалары (акчаларның булырга мөмкин чыганаклары буларак фаразлана).

## IX. Программаны тормышка ашыру белән идарә итү системасы

Программа чараларын тормышка ашыру белән оештыру-методик идарәне дәүләт заказчысы һәм координатор булган Министрлык гамәлгә ашыра.

Министрлык программа гамәлләрен әзерләү һәм тормышка ашыру буенча килештерелгән эш башкаруны тәэмин итә.

Программа гамәлләрен тормышка ашыру мониторингын һәм Программаны тормышка ашыруда катнашучы учреждениеләр һәм оешмалар эшчәнлеген, шулай ук аларның Программа гамәлләрен тормышка ашыру буенча килешенгән гамәлләрен координацияләүне Министрлык башкара.

"2017 – 2020 елларга Татарстан Республикасында эш башлаучы фермерларга ярдәм" Программасына
1 нче кушымта

РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ
АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК МИНИСТРЛЫГЫ

# СЕРТИФИКАТ

Серия НФ-16 № ______

***Әлеге сертификат белән***

__________________________________________________________________,
***(фамилиясе, исеме, атасы исеме)***

__________________________________________________________________
***(сериясе һәм номеры, кем тарафыннан һәм кайда бирелгән)***
***Россия Федерациясе гражданы паспортына һәм***

______________________________________________________________
***(ОГРНИП номеры һәм датасы)***
***крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәве турында таныклыгына ия булучы,***
***Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 20___ елның ________, ___-пр номерлы боерыгы белән расланган "2017 – 2020 елларга Татарстан Республикасында эш башлаучы фермерларга ярдәм" программасында катнашучы буларак таныклана һәм ана ________________муниципаль районында крестьян (фермер) хуҗалыгы үстерүгә ____________(________________________________) сум күләмендә грант бирелә***
***(хәрефләр белән язылган сумма)***

***Әлеге сертификат Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының _____елның ________ ___-пр номерлы боерыгы нигезендә бирелде***

Бирелү датасы _______________. 201___ ел

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары –
Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы
һәм азык-төлек министры М.Г. Әхмәтов

2017 елның ___мартындагы ______номерлы
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек
министрлыгы боерыгы белән расланган
Программага
2 нче кушымта

**Программаның максаты, бурычы, нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары һәм Программа чараларын финанслау**

| Максатның исеме | Бурычның исеме | Төп чаралар исеме | Башкаручылар | Чараларны башкару вакыты | Соңгы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, исәп берәмлекләре | Индикаторларның билгеләмәләре | | | | Финанслау, мең сумнарда | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019ел | 2020 ел |
| ТР КФХ үстерүне кызыксындыру | КФХ төзеп һәм үстереп, авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүне арттыру | КФХ төзүгә һәм үстерүгә грантлар бирү; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 8 апрелендәге 235 номерлы карары белән расланган "2013 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал, азык-төлек базарларын җайга салу" дәүләт программасында каралган чараларда катнашу | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы | 2017-2020 еллар | Төзелгән КФХ саны, берәмлек | 70 | 70 | 70 | 70 | Барлыгы 155,6 шул исәптән: ТР бюджеты - 40,0; федераль бюджет - 100,0; җәлеп ителгән акчалар 15,6. | Барлыгы 155,6 шул исәптән: ТР бюджеты – 40,0; федераль бюджет 100,0; җәлеп ителгән акчалар - 15,6. | Барлыгы – 155,6 шул исәптән: ТР бюджеты – 40,0; федераль бюджет - 100,0; җәлеп ителгән акчалар - 15,6. | Барлыгы - 155,6 шул исәптән: ТР бюджеты – 40,0; федераль бюджет -100,0 җәлеп ителгән акчалар - 15,6 |
| | | | | | Өстәмә булдырылатorган эш урыннары саны | 140 | 140 | 140 | 140 | | | | |

2017 елның ___ мартындагы ________/2-пр номерлы ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы боерыгы белән расланды

**Крестьян (фермер) хуҗалыкларын төзүгә һәм үстерүгә конкурс уздыру турында нигезләмә**

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Агросәнәгать комплексын үстерүнең региональ программалары максат күрсәткечләренә ирешүгә ярдәм итү өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү турында” 2016 елның 30 декабрендәге 1556 номерлы карарына һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “2017 елга агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында” 2017 елның 10 февралендәге 77 номерлы карарына ярашлы рәвештә әзерләнде.

Әлеге Нигезләмә дәүләт ярдәме күрсәтү тәртибен, проектларны сайлап алу критерииләрен, проектларны конкурс нигезендә сайлап алуның максатларын, шартларын, оештыру процедурасын билгели.

Әлеге Нигезләмәдә кулланыла торган төп төшенчәләр:

**эш башлаучы фермер** – әлеге Нигезләмәгә ярашлы рәвештә сайлап алынган Программада катнашучы;

**гариза бирүче** – Программада катнашучы дип тану өчен конкурс комиссиясенә гариза бирүче һәм әлеге Нигезләмә таләпләренә туры килүче крестьян (фермер) хуҗалыгы (алга таба – КФХ) башлыгы;

**крестьян (фермер) хуҗалыгын төзүгә һәм үстерүгә грант** – федераль бюджеттан, Татарстан Республикасы бюджетыннан түбәндәгечә КФХ башлыгы хосусый счетына күчерелә торган акчалар:

ЕГРЮЛ реестрында теркәлгән эш башлаучы фермерның Федераль казначылык органының Татарстан Республикасы буенча территориаль бүлегендә ачылган хосусый счетына;

ЕГРИП реестрында теркәлгән эш башлаучы фермерның Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яки кредит оешмаларында ачылган хосусый счетына

Татарстан Республикасы авыл җирлекләре территориясендә һәм авылара территорияләрдә КФХ төзү һәм үстерү максатларында Программа нигезендә дәүләт ярдәменең бүтән юнәлешләре кысаларында кайтарылмый торган чыгымнарын финанслашу өчен, түбәндәгеләрне кертеп:

авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән җир кишәрлекләрен сатып алу;

авыл хуҗалыгы терлекләрен асрау, авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү, саклау һәм эшкәртү өчен кирәк булган җитештерү һәм саклау биналарын, урыннарын төзү (реконструкцияләү) өчен проект документларын эшләү;

авыл хуҗалыгы терлекләрен асрау, авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү, саклау һәм эшкәртү өчен кирәк булган җитештерү һәм саклау биналарын, урыннарын, өстәмә корылмаларны, инженер челтәрләрен, киртәләрне һәм корылмаларны сатып алу, төзү, ремонтлау һәм яңадан төзү, шулай ук аларны теркәү;

авыл хуҗалыгы терлекләрен асрау, авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү, саклау һәм эшкәртү өчен кирәк булган җитештерү һәм саклау объектларына алып килә торган юлларны һәм керү юлларын төзү;

авыл хуҗалыгы терлекләрен асрау, авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү, саклау һәм эшкәртү өчен кирәк булган җитештерү һәм саклау биналарын, урыннарын, өстәмә корылмаларны һәм төзелмәләрне инженер челтәрләренә - электр, су, газ һәм җылылык челтәрләренә, юл инфраструктурасына тоташтыру;

авыл хуҗалыгы терлеген сатып алу;

авыл хуҗалыгы техникасын һәм инвентарен, йөк автомобиле транспортын, авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү һәм эшкәртү өчен җиһазлар сатып алу;

күпьеллык үсемлекләр утырту өчен орлыклар һәм утырту материалларын сатып алу;

ашлама һәм агулы химикатлар сатып алу.

**конкурс комиссиясе** – крестьян (фермер) хуҗалыкларын төзүгә һәм үстерүгә грантлар бирү өчен КФХ проектларын сайлап алу максатларында төзелгән ведомствоара конкурс комиссиясе;

**экспертлар советы** – гаризаларны карап тикшерү һәм аннары документларны конкурс комиссиясенә тапшыру өчен Министрлык тарафыннан төзелгән совет;

**чыгымнар планы –** грант акчаларын тоту юнәлешләре буенча чыгымнарның гариза бирүче тарафыннан конкурс комиссиясе раславына тапшырылган статьялы сметасы;

**грант алучы** – Программада катнашучы дип тану өчен конкурс сайлавын узган һәм грант алуга шартнамә төзегән КФХ башлыгы.

1.2. Грант гаризасы конкурс комиссиясе тарафыннан расланган КФХ башлыгына бирелә.

1.3. Конкурс комиссиясе эшен оештыруны Министрлык башкара.

1.4. Грант чыгымнар планында күрсәтелгән сатып алына торган мөлкәт, башкарыла торган эшләр атамалары буенча куелган хакның кимендә 10 процентын үз акчалары исәбеннән түләү йөкләмәсен алган КФХ башлыкларына бирелә.

Грант хисабына КФХ башлыгы тарафыннан сатып алынган мөлкәт грант акчаларын тоткан көннән башлап 5 ел дәвамында сатылырга, бүләк ителергә, арендага тапшырылырга, башка затлар файдалануына бирелергә, алмаштырылырга яки пай, кертем рәвешендә кертелергә яисә Россия Федерациясе законнары нигезендә башка төрле тартып алынырга тиеш түгел. Бу шарт гаилә терлекчелек фермаларын һәм терлекчелек продукцияләрен эшкәртү предприятиеләрен үстерүгә грантлар бирү чараларында катнашучылар өчен җитди булып тора.

## 2. Грант күләме һәм бирү шартлары

2.1. Грантлар грант алучыларга техник-икътисадый нигезләүгә ярашлы рәвештә максатчан чыгымнарны финанслашу шартларында кире кайтарылмый торган итеп гаилә терлекчелек фермаларын үстерүгә бирелә.

2.2. Грант күләме конкурс комиссиясе тарафыннан КФХның үз акчаларын һәм аның чыгымнар планын исәпкә алып билгеләнә. Грант күләме чыгымнар планында күрсәтелгән чыгымнарның 90 процентыннан артык булмый.

Ит яки сөт өчен мөгезле эре терлек үрчетүгә грантның максималь күләме 3,0 млн. сум, эшчәнлекнең башка төрләрен алып баруга иң күбе 1,5 млн.сум була.

2.3. Грантлар проектка салынган куәтләр түбәндәгечә булганда бүлеп бирелә:

кимендә 24 баш сыеры булган (елына кимендә 110 тонна сөт) сөт фермаларына;

кимендә 50 баш мөгезле эре терлекне (тере авырлыкта елына кимендә 12 тонна ит) сугымга симертү фермаларына;

кимендә 100 дуңгыз, шул исәптән 5 ана дуңгыз булган (тере авырлыкта елына кимендә 10 тонна ит) дуңгыз фермаларына;

кимендә 150 баш сарык, шул исәптән кимендә 50 баш ана сарык булган (тере авырлыкта елына кимендә 4 тонна ит) сарыклар үрчетү фермаларына;

кимендә 40 баш савым кәҗәләренә (елына кимендә 30 тонна сөт);

ит өчен кош-корт үстерүче кош фермаларына – ит житештерүнең еллык әйләнеше тере авырлыкта кимендә 4 мең баш күркә (кимендә 30 тонна), 5 мең баш бройлер (кимендә 5 тонна), 1,5 мең баш каз (кимендә 5 тонна), 3 мең баш үрдәк (кимендә 6 тонна) булганда;

йомырка өчен кош-корт үстерүче кош фермаларына – йомырка салучы кимендә 5 мең баш тавык (елына кимендә 1,3 млн. данә), 10 мең баш бытбылдык (елына кимендә 2,5 млн. данә), 1 мең баш каз (елына кимендә 75 мең данә) яки 1 мең баш үрдәк (елына кимендә 120 мең данә) булганда;

яшь кош-корт үстерүче кош фермаларына – тере авырлыктагы артымның еллык әйләнеше кимендә 5 мең баш күркә (кимендә 5 тонна), 5 мең баш бройлер (кимендә 1,5 тонна),6 мең баш йомырка тавыгы (кимендә 5 тонна), 2,5 мең баш каз (кимендә 0,6 тонна) яки 5 мең баш үрдәк (кимендә 1,5 тонна) булганда;

кимендә 40 ат, шул исәптән кимендә 16 бия булган (тере авырлыкта елына кимендә 2,5 тонна ит) ат фермаларына;

бәрәңге үстерү мәйданы кимендә 10 га булганда;

ачык грунтта яшелчәчелек кимендә 5 га булганда;

ябык грунтта яшелчәчелек кимендә 1000 $м^2$ булганда;]

бөртекле һәм бөртекле-кузаклы культуралар, азык культуралары җитештерү кимендә 100 га булганда;

жимеш һәм җиләк культуралары үстерү кимендә 1,3 га булганда.

2.4. Грантлар тиешле елга һәм план чорына федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты турында законнарда Министрлыкка бу максатларга каралган бюджет акчалары чикләрендә бирелә.

2.5. Конкурста катнашу өчен КФХ түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

а) КФХ башлыгы Россия Федерациясе гражданы, житештерү эшчәнлегендә шәхси катнаша;

б) конкурска гариза бирү датасына КФХ эшчәнлеге срогы теркәлү датасыннан 24 айдан артып китми;

в) КФХ Татарстан Республикасы муниципаль районның авыл җире территориясендә теркәлгән һәм шунда җитештерү эшчәнлеген башкара, КФХ башлыгы КФХ урнашкан һәм теркәлгән урын буенча муниципаль берәмлектә даими яши яки даими яшәү урынына күчергә йөкләмә ала, һәм әлеге хуҗалык грант алган һәм грант акчаларын тотып бетергән датадан 5 ел дәвамында бердәнбер эш урыны булып тора;

г) КФХ башлыгы элек түбәндәгеләрне алмаган:

крестьян (фермер) хуҗалыгын төзүгә һәм үстерүгә грант;

гаилә терлекчелек фермаларын үстерүгә грант;

д) КФХ башлыгы соңгы өч ел эчендә индивидуаль эшкуар буларак эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашырмаган һәм (яки) коммерциягә караган оешманың гамәлгә куючысы (катнашучысы) булмаган, моңа конкурс комиссиясенә гариза биргән вакытка үзе башлык булып торган крестьян (фермер) хуҗалыгы керми. Гариза бирүче грант алуга конкурста катнашуга гаризаны эшкуарлык эшчәнлегенең гомуми срогы соңгы өч елда барлыгы иң күбе 6 ай тәшкил итсә генә бирә ала;

е) КФХ башлыгының урта махсус яки югары авыл хуҗалыгы белеме бар, яки авыл хуҗалыгы белгечлеге буенча өстәмә һөнәри белем алган, яки авыл хуҗалыгында өч елдан да ким булмаган эш стажы бар, яки кимендә өч ел дәвамында шәхси ярдәмче хуҗалык алып баруны яки уртак алып баруны гамәлгә ашыра;

ж) КФХ "Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында" Федераль закон нигезендә микропредприятие критерийләренә туры килә;

з) КФХның Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 8 апрелендәге 235 номерлы карары белән расланган "2013-2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал, азык-төлек базарларын җайга салу" дәүләт программасында билгеләнгән эшчәнлек (гармак) юнәлешләре буенча хуҗалыкны төзү һәм үстерү, сатыла торган авыл хуҗалыгы продукциясе күләмен арттыру буенча кимендә биш ел срокка каралган планы бар;

и) КФХның сатып алына торган мөлкәт, башкарыла торган эшләр, күрсәтелә торган хезмәтләр исеме, аларның саны, бәясе, финанслау чыганаклары (грант акчалары, үз акчалары) күрсәтелгән чыгымнар планы бар;

к) КФХ грант алган елда грант ярдәменең һәр 1,0 млн. сумына кимендә бер яңа даими эш урынын, әмма бер грантка кимендә бер яңа даими эш урынын булдыруны планлаштыра;

л) КФХ яңа булдырылган даими эш урыннарын грант акчаларын тотып бетергәннән соң кимендә биш ел дәвамында саклап калу йөкләмәсен ала;

м) КФХ грант акчаларын тотып бетергәннән соң кимендә биш ел дәвамында эшчәнлек башкарырга йөкләмә ала;

н) КФХ башлыгы һәм әгъзалары Россия Федерациясе законнары нигезендә үзләренең персональ белешмәләрен тапшыруга һәм эшкәртүгә ризалык бирәләр;

о) КФХ башлыгы, авырып киткән, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә чакырылган яки хуҗалыкта булмавына яисә КФХ эшчәнлегендә шәхси катнаша

алмавына бәйле алдан билгеле булмаган башка шартлар туган очракта, Министрлык белән килештереп, хуҗалык белән житәкчелек итүне һәм грант алуга бәйле бурычларын үтәүне, грант хисабына сатып алынган мөлкәтне сату хокукын бирмичә, үзенең туганына яки КФХ әгъзасына тапшыру йөкләмәсен ала;

п) КФХ чыгымнар планында күрсәтелгән сатып алына торган мөлкәт, башкарыла торган эшләр, күрсәтелә торган хезмәтләр бәясенең кимендә 10 процентын үз акчалары хисабына түләргә йөкләмә ала;

р) КФХ башлыгы акчалар хуҗалык башлыгы счетына килгән көннән соң 18 ай эчендә грант акчаларын тотып бетерергә һәм грант хисабына сатып алынган мөлкәтне бары тик хуҗалыкны үстерүдә файдаланырга йөкләмә ала;

с) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына Россия Федерациясе законнары нигезендә түләү срогы житкән салымнар, җыемнар һәм башка түләү йөкләмәләре юк, шулай ук Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетына шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән субсидияләрне, бюджет инветицияләрен кайтару буенча вакыты узган бурычлар һәм Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетларына кайтарылырга тиешле вакыты узган башка бурычлар юк;

т) КФХ карата үзгәртеп кору, юкка чыгару, яки банкротлык процедуралары үткәрелми һәм хуҗалык эшчәнлеген башкарырга чикләүләр юк;

у) КФХ әлеге Нигезләмәнең 2.6 пунктында күрсәтелгән максатларга башка норматив хокукый актлар, муниципаль хокукый актлар нигезендә Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетыннан акча алучы булып тормый;

ф) КФХ 30 мең сумнан күбрәк суммага авыл хуҗалыгы продукциясен сату турында гражданлык-хокукый шартнамәләр (башлангыч шартнамәләр) төзегән.

2.6. Грант чыгымнар планы нигезендә Грант алучы тарафыннан түбәндәгеләргә тотылырга мөмкин:

авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән җир кишәрлекләрен сатып алуга;

авыл хуҗалыгы терлекләрен асрау, авыл хуҗалыгы продукциясен житештерү, саклау һәм эшкәртү өчен кирәк булган житештерү һәм саклау биналарын, урыннарын төзү (реконструкцияләү) өчен проект документларын эшләүгә;

авыл хуҗалыгы терлекләрен асрау, авыл хуҗалыгы продукциясен житештерү, саклау һәм эшкәртү өчен кирәк булган җитештерү һәм саклау биналарын, урыннарын, өстәмә корылмаларны, инженер челтәрләрен, киртәләрне һәм корылмаларны сатып алуга, төзүгә, ремонтлауга һәм яңадан төзүгә, шулай ук аларны теркәү эшләренә;

авыл хуҗалыгы терлекләрен асрау, авыл хуҗалыгы продукциясен житештерү, саклау һәм эшкәртү өчен кирәк булган житештерү һәм саклау объектларына алып килә торган юлларны һәм керү юлларын төзүгә;

авыл хуҗалыгы терлекләрен асрау, авыл хуҗалыгы продукциясен житештерү, саклау һәм эшкәртү өчен кирәк булган житештерү һәм саклау биналарын, урыннарын, өстәмә корылмаларны һәм төзелмәләрне инженер челтәрләренә - электр, су, газ һәм жылылык челтәрләренә, юл инфраструктурасына тоташтыруга;

авыл хуҗалыгы терлеген сатып алуга;

авыл хуҗалыгы техникасын һәм инвентарен, йөк автомобиле транспортын, авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү һәм эшкәртү өчен җиһазлар сатып алуга;

күпьеллык үсемлекләр утырту өчен орлыклар һәм утырту материалларын сатып алуга;

ашлама һәм агулы химикатлар сатып алуга.

2.7. Грант КФХга бары тик бер генә тапкыр бирелергә мөмкин.

2.8. КФХ башлыгы бурычлары:

грант акчаларын тотып бетергәннән соң 5 ел дәвамында Министрлыкка квартал саен 9 нчы кушымта нигезендә "Эшчәнлек турында белешмәләр" хисабын тапшыру;

чыгымнар планы нигезендә грант акчаларын һәм үз акчаларын тотып бетергәннән соң, 12 нче кушымтада каралган "Җыелма реестр"ны, акчаларның максатка ярашлы рәвештә тотылуын раслый торган финанс хисабы документларын тапшыру (грант акчаларының йөрешен раслый торган исәп-хисап счетыннан банк өземтәсе, сату-лу шартнамәләре, түләү йөкләмәләре, накладнойлар, счет-фактуралар, фото).

## 3. Программада катнашу өчен конкурс комиссиясенә тапшырыла торган документлар исемлеге

3.1. Программада катнашу өчен гариза бирүчеләр түбәндәге документларны тапшыралар:

3.1.1. Әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымтада каралган форма буенча гариза;

3.1.2. Әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымтада каралган форма буенча анкета;

3.1.3. Түбәндә санап кителгән документларның кимендә берсе:

а) гариза бирүченең урта махсус яки югары авыл хуҗалыгы белеме булуын раслый торган белем турында документ күчермәсе;

б) гариза бирүченең авыл хуҗалыгы белгечлеге буенча өстәмә һөнәри белем бирү курсларын тәмамлавын раслый торган документ күчермәсе;

в) гариза бирүченең шәхси ярдәмче хуҗалыкны үзе тарафыннан яки уртак нигездә кимендә өч ел дәвамында алып баруы турында җирле үзидарә органы тарафыннан таныкланган хуҗалык кенәгәсеннән өземтә;

г) гариза бирүченең авыл хуҗалыгында авыл хуҗалыгы белгечлеге буенча кимендә 3 ел эш стажы булуын раслый торган хезмәт кенәгәсе күчермәсе, шул ук вакытта хезмәт кенәгәсенең төп нөсхәсе әлеге Нигезләмәнең 2.5. (в) пунктына туры килүен билгеләү өчен мәҗбүри күрсәтелә.

3.1.4. Фермер хуҗалыгын югары технологияле җиһазлар һәм авыл хуҗалыгы техникасын кулланып төзү һәм үстерү буенча, сату каналларын күрсәтеп, терлекчелек һәм үсемлекчелек продукциясенең сатылу күләмен арттыруга юнәлтелгән, төзелеш, реконструкция яки модернизация буенча барлык чыгымнарын биш елдан күп булмаган вакыт эчендә каплый алуы нигезләнгән, шулай ук, сатып алына торган мөлкәтнең, башкарыла торган эшләрнең, күрсәтелә торган хезмәтләрнең атамаларын, аларның исәбен, бәясен, финанслау чыганакларын

кәгазьдә һәм электрон чыганакларда күрсәтеп, грант хисабына финанслашу күздә тотылган акчалар чыгымнары планы проекты булган әлеге Нигезләмәгә 3 нче кушымтада каралган бизнес-план;

3.1.5. Конкурс гаризасы биргән көннән иң күбе өч ай элек алынган Индивидуаль эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;

3.1.6. КФХны дәүләт теркәве турында таныклык күчермәсе йә "Индивидуаль эшкуарларның бердәм дәүләт реестрындагы язма бите" (Форма № Р60009);

3.1.7. Федераль дәүләт статистика хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органында дәүләт теркәве турында таныклыкның булу хаты күчермәсе;

3.1.8. Россия Федерациясе гражданы паспорты күчермәсе;

3.1.9. Әлеге Нигезләмәгә 4 нче кушымтада каралган форма буенча КФХ үстерүгә грант хисабына финаслашуга тәкъдим ителә торган чыгымнар планы;

3.1.10 Сатып алына торган һәр молкәт, башкарыла торган эш бәясенең кимендә 10 проценты күләмендә КФХның акчасы булуны раслый торган КФХ исәп-хисап счетыннан банк өземтәсе;

3.1.11. Эш башлаучы фермерның "Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында" 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясы таләпләре буенча микропредприятие параметрларына туры килүен раслый торган әлеге Нигезләмәгә 5 нче кушымтада каралган форма буенча эшчеләрнең уртача саны турында белешмә;

3.1.12. 30 мең сумнан артык суммага авыл хуҗалыгы продукциясен сату турында башлангыч килешү;

3.1.13. Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан аерым затның хуҗалыгындагы (хуҗалыгында булган) күчемсез молкәт объектларына хокуклары турында оземтә, ул вәкаләтле орган тарафыннан таныкланган булырга һәм конкурс гаризасы биргән көннән иң күбе 30 көн элек алынган булырга тиеш;

3.1.14. Локаль сметалар һәм үз-үзен җайга салучы оешмага (алга таба – ҮҖО) проектлау эшләренә бирелгән рөхсәтнең күчермәсе белән бергә (грант төзелешкә яки реконструцияләүгә тотылганда) терлекчелек фермасының схема-сызымы (эшләр башкарылачак урынның фотосы, объект булган очракта – аның эчке һәм тышкы яклары фотосы) теркәлгән җыелма смета исәп-хисабы;

3.1.15. Төзүгә (реконструкцияләүгә) рөхсәт (грант төзүгә яки реконструкцияләүгә тотылганда), яки милек хокукы турында таныклык, яки фермага аренда шартнамәсе, алар барысы да законнарда билгеләнгән итәртиптә теркәлгән булырга тиеш;

3.1.16. Салым органыннан, үзе теләп, конкурска гариза бирелә торган айның беренче числосына яки аңа кадәрге айга Россия Федерациясе законнары нигезендә үтәлү срогы җиткән Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча түләү вакыты узган бурычлары булмауны раслый торган белешмәне (КНД 1120101 коды буенча форма). Күрсәтелгән документ субсидия алучы тарафыннан үз теләге белән тапшырылмаган очракта, Министрлык аны ведомствоара мәгълүмат алмашу тәртибендә салым органыннан соратып ала;

3.1.17. Әлеге Нигезләмәгә 6 нчы кушымтада каралган форма буенча персональ белешмәләрне эшкәртүгә ризалык;

3.1.18. КФХ башлыгының КФХ эшчәнлеген алып барыла торган муниципаль берәмлеккә даими яшәү урынына күчү турында йөкләмә (башка муниципаль берәмлектә яшәгән очракта);

3.1.19. КФХ башлыгының хезмәт кенәгәсе күчермәсе;

3.1.20. Законнарда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән жир кишәрлегенә милекчелек хокукларын һәм (яисә) жир кишәрлеген арендалау шартнамәсен дәүләт теркәве турында таныклык күчермәсе;

3.1.21. КФХ урнашу урыны буенча салым органына исәпкә кую турында таныклык күчермәсе;

3.1.22. Соңгы хисап датасына “Терлекчелек продукциясен житештерү һәм терлекнең баш саны турында белешмәләр” 3-фермер номерлы формасы буенча хисап.

3.1.23. 11 нче кушымтада каралган йөкләмә.

3.2. Белешмәләрнең дөреслеге һәм тапшырылган документларның чын булуы өчен жаваплылык КФХ башлыгына йөкләнә. Конкурс комиссиясенә документлар әзерләү һәм тапшыру белән бәйле барлык чыгымнарны КФХ башлыклары түли.

Таныклау таләп ителгән һәм берничә биттән гыйбарәт документлар тапшырылганда, аларның һәр бите таныклана. Документларның төп нөсхәләре проектны яклаганда конкурс комиссиясендәге күчермәләр белән чагыштырып карау өчен бирелә.

Әлеге Нигезләмәнең 3.1. бүлегендә күрсәтелгән документлар КФХ башлыгы тарафыннан имзаланган, тегелгән, номерлар сугылган һәм КФХ башлыгы мөһере белән таныкланган булырга тиеш. Вәкаләтле вәкил мөһере белән расланган һәм имзасы белән таныкланган (юридик затлар өчен) яки үз кулы белән таныкланган (КФХ башлыгы өчен) төзәтүләрдән тыш башка бетерүләр һәм төзәтүләр рөхсәт ителми.

Әлеге Нигезләмәнең 3.1. бүлегендә күрсәтелгән документлар конкурс сайлавын уздыру турындагы белдерүдә күрсәтелгән вакыт эчендә һәм адрес буенча тапшырыла.

Грантлар бирү тәртибе һәм документларның формалары турында мәгълүмат “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Авыл хужалыгы һәм азык-төлек министрлыгының рәсми сайтына http: //agro.tatarstan.ru/, “Фермерларга, авыл хужалыгы кооперативларына грантлар һәм ЛПХ субсидияләр” бүлегенә, андагы “Россия Федерациясе бюджеты катнашында гаилә фермаларына ярдәм” бүлекчәсенә урнаштырыла.

Гариза бирүче конкурс комиссиясенә (турыдан-туры әңгәмә вакытында), үз ихтыяры белән) КФХна программаның потенциаль катнашучы буларак уңай бәя бирә торган, конкурс комиссиясенә йогынты ясый алган түбәндәге документлар тапшырырга мөмкин:

а) муниципаль хакимият органнарынннан КФХ үсешен, аның житештерү күрсәткечләре динамикасын, шулай ук булырга мөмкин социаль-икътисадый

нәтиҗәне һәм грант бирүнең максатка ярашлы булуын күрсәтә торган тәкъдим хатлары;

б) авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге объектларга милекчелек хокукларын дәүләт теркәве турында таныклыкнын күчермәсе, техник чара паспортынын күчермәсе (милкендә техник чара булганда);

в) житештерү биналары (шул исәптән төгәлләнмәгән төзелеш), авыл хуҗалыгы терлеге, техникасы һәм җиһазлары фотосы;

г) гариза биргән вакыттан әлеге Нигезләмәнең 2.5. һәм 3.1. пунктларында билгеләнгән таләпләргә туры китереп эшләп бетерелгән документлар;

д) массакүләм мәгълүмат чараларында басылып чыккан мәкаләләр һәм үзе кирәк дип тапкан башка документлар.

## IV. Гаризаларны кабул итү һәм карау

4.1. Грантлар бирү буенча конкурс сайлавында катнашуга гаризалар кабул ителә башлау турында белдерү "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Министрлыкнын http:/ agro.tatarstan.ru/ рәсми сайтында "Фермерларга, авыл хуҗалыгы кооперативларына грантлар һәм ЛПХ субсидияләр" бүлегенә урнаштырыла:

Белдерүдә конкурс уздырылу урыны һәм вакыты (кимендә 30 календарь көн), элемтәгә керү өчен телефоннар, Министрлык сайтының документларны тапшыру тәртибе һәм конкурс шартлары турында мәгълүмат алырга, норматив документлар белән танышырга мөмкин булган бүлеге күрсәтелә.

4.2. Гаризалар кабул ителә башлау көне дип белдерү бастырылган көннән соң килә торган көн санала. Белдерүдә күрсәтелгән срок узганнан соң, КФХ башлыкларыннан гаризалар кабул ителми. Гаризалар кимендә 30 календарь көн эчендә кабул ителә.

Алынган гаризалар һәм документларны теркәү гаризаларны теркәү журналына язылып баруына карап башкарыла, ул номерланган, тегелгән һәм конкурс комиссиясе секретаре имзасы һәм Министрлык мөһере белән беркетелгән булырга тиеш. Гаризаны теркәгәндә аңа керү номеры сугыла.

Әлеге Нигезләмәнең 3.1. бүлегендә күрсәтелгән документлар конкурс комиссиясе секретарена кәгазьдә тапшырыла, өстәмә буларак электрон рәвештә әлеге Нигезләмәнең 3.1.7. (бизнес-план), 3.1.11. (локаль-смета исәп-хисаплары һәм КФХда хәзерге вакытта булган житештерү биналары, техника, терлек һәм кош-корт фотодокументлары) һәм 3.1.15. (анкета) пунктчаларында күрсәтелгән документлар тапшырыла. Конкурс комиссиясенә КФХ башлыгы тарафыннан тапшырыла торган барлык документларның исемнәре, алардагы битләр саны ике нөсхәдә төзелә торган исемлеккә кертелә. Конкурс комиссиясе секретаре тапшырылган документларны аларга кушымта итеп бирелгән исемлек белән (7 нче кушымта) чыгыштырып караганнан соң, алар, булган очракта, КФХ мөһере белән таныклана торган конвертка салыналар. Конвертта шулай ук программаның исеме, ферманың эшчәнлек юнәлеше һәм аның проекттагы куәте, КФХ исеме, гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм адресы күрсәтелә. Материаллар исемлеге

конвертка салынмый. Документларны кабул иткәндә, исемлек битенә документларның кабул ителүен раслый торган тамга салына, кабул итү датасы һәм теркәлү номеры күрсәтелә. Кабул ителү турында тамга салынган исемлек битенең бер нөсхәсе КФХ башлыгында кала, ә икенчесе документлар пакетына беркетеп куела.

Гаризаны һәм документларны кабул иткәндә аларның тулылыгын һәм куелган таләпләргә туры килү-килмәвен тикшерү башкарылмый

## 5. Конкурс комиссиясенен функцияләре һәм бурычлары

5.1. Конкурс комиссиясе үз эшчәнлеген законнарга, әлеге Нигезләмәгә таянып башкара һәм үз эшен авыл хуҗалыгы товарларын житештерүчеләргә дәүләт ярдәме инфраструктурасын тәшкил итә торган оешмалар, иҗтимагый оешмалар, крестьян (фермер) хуҗалыклары һәм агрария профиле буенча белем бирүче оешмалар белән үзара хезмәттәшлектә торып оештыра.

5.2. Конкурс комиссиясенең төп бурычлары:

эш башлаучы фермерларга ярдәм итүгә грант алу өчен гариза бирүче тарафыннан тапшырыла торган конкурс документациясен үз вакытында, ачык һәм объектив карауны тәэмин итү;

проектларга аларның тулылыгын һәм дөреслеген, икътисадый нәтиҗәлелеген, Татарстан Республикасы икътисады өчен социаль әһәмиятле булуын һәм дәүләт ярдәме күрсәтүнең максатка ярашлы булуын билгеләү максатында экспертиза ясау;

конкурсның җиңүчеләрен һәм аларга бирелә торган грантларның күләмнәрен билгеләү.

5.3. Конкурс комиссиясе Министрлык боерыгы белән кимендә 12 кешедән төзелә һәм конкурс комиссиясе рәисеннән, рәис урынбасарыннан, секретареннан (тавыш бирү хокукы юк) һәм әгъзаларыннан гыйбарәт була. Конкурс комиссиясе составына дәүләт хезмәткәрләре һәм муниципаль хезмәткәрләр, авыл хуҗалыгы өлкәсендә иҗтимагый оешмалар, берлекләр, берләшмәләр һәм мәгариф оешмалары вәкилләре кертелә. Конкурс комиссиясе составындагы дәүләт хезмәткәрләренең һәм муниципаль хезмәткәрләрнең саны 50 процентган кимрәк була.

Конкурс нәтиҗәләрендә үз мәнфәгатьләре булган затлар (шул исәптән конкурста катнашуга гариза бирүчеләр йә күрсәтелгән гаризаларны биргән КФХда торучылар), йә конкурста катнашучылар йогынты ясый алган затлар комиссия әгъзалары була алмый.

Конкурс комиссиясе рәисе:

конкурс комиссиясе эшчәнлегенә җитәкчелек итә һәм аңа йөкләнгән бурычларның үтәлеше өчен җавап бирә;

конкурс комиссиясе әгъзалары арасында йөкләмәләр бүлә;

конкурс комиссиясе утырышларын алып баруны, утырышлар беркетмәләре әзерләнүне һәм конкурс комиссиясе тарафыннан кабул ителгән карарларның үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыра.

5.4. Конкурс комиссиясе рәисе урынбасары, конкурс комиссиясе утырышында рәис булмаган очракта, аның вазыйфаларын башкара.

5.5. Конкурс комиссиясе секретаре:

гаризалар кабул ителеп беткәннән соң биш эш көне эчендә конкурс комиссиясе утырышында каралырга тиешле гаризаларның, аларга кушып тапшырылган документлары белән бергә, исемлеген төзи;

гаризалар кабул ителеп беткәннән соң биш эш көне эчендә документларны электрон рәвештә экспертлар советы каравына тапшыра;

конкурс комиссиясе утырышының кон тәртибе буенча материаллар әзерләүне оештыра, документлар әйләнешен һәм утырышларда конкурс комиссиясе әгъзаларының катнашуын, конкурс комиссиясе утырышлары беркетмәләрен рәсмиләштерүне тәэмин итә;

гаризалар кабул ителеп беткәннән соң 15 эш көне эчендә конкурс комиссиясе утырышын гариза бирүчеләрне турыдан-туры әңгәмәгә чакырып оештыра;

конкурс тәмамланганнан соң 30 эш көне эчендә барлык гаризаларны һәм документларны, шулай ук конкурс комиссиясе тарафыннан кабул ителгән барлык документларны, грант акчалары тотып бетерелгән датадан биш ел дәвамында саклау максатыннан, Министрлык архивына тапшыра.

5.6. Йөкләнгән вәкаләтләрне, консультацияләрне гамәлгә ашыру, тапшырылган документларга экспертиза ясау өчен конкурс комиссиясе экспертлар советын җәлеп итә. Экспертлар советы Министрлык боерыгы белән кимендә 12 кешедән төзелә һәм экспертлар советы рәисеннән, секретареннан һәм әгъзаларынанн гыйбарәт була.

Экспертлар советы:

конвертларны ача һәм документларның булуын тикшерә;

КФХ башлыгының һәм аның тарафыннан тапшырылган документларның таләпләргә туры килүен тикшерә

Экспертлар советы рәисе:

экспертлар советы эшчәнлегенә житәкчелек итә һәм аңа йөкләнгән вазыйфаларның үз вакытында үтәлүе өчен жаваплы була;

экспертлар советы әгъзалары арасында йөкләмәләр бүлә;

бәяләү ведомостенә кертеп, балларның исәбен саный.

Экспертлар советы рәисе урынбасары, экспертлар советы рәисе булмаган очракта, аның вазыйфаларын башкара.

Экспертлар советы секретаре экспертлар советы утырышын һәм конкурс комиссиясе өчен экспертлар советы бәяләмәсен әзерләү эшен оештыра.

Экспертлар советы утырышы КФХ башлыкларының конкурска гаризаларын кабул итү төгәлләнгән көннән 5 эш көненнән дә соңга калмыйча уздырыла.

Рәис яки (ул булмаган очракта) рәис урынбасары экспертлар советы утырышларын уздыру вакытын һәм урынын билгели, шулай ук аларның көн тәртибен раслый, эксперт советы утырышы беркетмәсен имзалый.

Утырышның чакырылуын экспертлар советы секретаре тәэмин итә. Экспертлар советы утырышын уздыру вакыты һәм урыны турында мәгълүмат, шулай ук утырышның көн тәртибе экспертлар советы әгъзаларына утырыш датасына кадәр ике көннән дә соңга калмыйча тапшырыла.

Экспертлар советы утырышы, анда экспертлар советы әгъзаларының кимендә яртысы булган очракта, тулы хокуклы була. Утырышта карала торган мәсьәләләр хакында фикер алышканда экспертлар советы әгъзаларының хокуклары тигез була.

Экспертлар советы карарлары Экспертлар советының утырышта катнашучы әгъзалары тавышларның гади күпчелегенә нигезләнеп кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, экспертлар советы рәисе яки (ул булмаган очракта) рәис урынбасары тавышы хәлиткеч була.

Экспертлар советы карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул экспертлар советы рәисе, экспертлар советы рәисе урынбасары, экспертлар советы секретаре һәм экспертлар советы әгъзалары тарафыннан имзалана.

Беркетмәдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

утырыш уздыру датасы һәм урыны;

утырышта катнашкан экспертлар советы әгъзаларының (фамилияләре, инициаллары) һәм башка затларның (фамилияләре, инициаллары, эшләгән вазыйфалары һәм эш урыннары) составы;

утырышның көн тәртибе;

кабул ителгән тәкъдимнәр.

Экспертлар советы конкурс комиссиясе каравына тәкъдим рәвешендәге бәяләмә чыгара.

5.7. Конкурс комиссиясе, гаризалар кабул итү тәгәлләнгән көннән 14 эш көненнән дә соңга калмыйча, конкурс комиссиясе утырышын үткәрә, гариза бирүчеләр тарафыннан тапшырылган документларны, аларның туры килүе турында экспертлар советы тәкъдимнәрен карый, грант суммасын билгели, КФХ башлыкларына грантлар бирү йә бирүдән баш тарту турында карар кабул итә, ул конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсе белән (алга таба – беркетмә) рәсмиләштерелә.

Турыдан-туры әңгәмә барышында конкурс комиссиясенең һәр әгъзасы гаризаларда бирелгән мәгълүматка һәм бирелә торган сорауларга гариза бирүченең җавапларына нигезләнеп, карар кабул итә һәм, бирелә торган грантның күләмен күрсәтеп, һәр КФХ башлыгы буенча тавыш бирү кәгазенә язма кертә.

5.8. Конкурс комиссиясе карары, конкурс комиссиясе составының яртысыннан күбрәге булганда, тавышларның гади күпчелегенә нигезләнеп кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, конкурс комиссиясе утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

Баллар санын бертигез җыйган берничә дәгъва итүче булып, катнашучыларның сан составы буенча тиешле грант саны булмаганда, грант “Конкурска гаризалар теркәүнең 3 номерлы журналы”нда алданрак теркәлгән гариза иясенә бирелә.

Конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан Тавыш бирү кәгазьләрендә күрсәтелгән карарларына нигезләнеп, секретарь конкурс бюллетенен төзи. Тавыш бирү кәгазьләре һәм конкурс бюллетене беркетмәгә беркетеп куела.

Конкурс комиссиясе утырышлары аны уздыруга ихтыяҗ булган саен үткәрелә. Конкурс комиссиясе әгъзалары утырышка рәис карары буенча чакырыла. Конкурс комиссиясе секретаре утырышка өч эш көне кала гариза бирүчеләрнең электрон

рәвештә тапшырылган, каралуы планлаштырылган документларын һәм экспертлар советы бәяләмәсен, өйрәнү өчен, конкурс комиссиясе әгъзаларына җибәрә.

Конкурс нәтиҗәләре турында мәгълүмат интернет челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтына конкурс комиссиясе карары кабул ителгән көннән 10 эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла.

5.9. Конкурс комиссиясе, экспертлар советы бәяләмәсенә һәм гариза бирүчеләр тарафыннан тапшырылган документларга ясалган анализга нигезләнеп, түбәндәге критерийларга карап, конкурс сайлавы җиңүчеләрен билгели:

| № т/б | Критерий исеме | Күрсәткечләр | Баллар белән бәяләү |
|---|---|---|---|
| 1 | Ферманың юнәлеше | сөт | 7 |
| | | мөгезле эре терлек симертү | |
| | | атчылык | 6 |
| | | кошчылык | |
| | | яшелчәчелек (ачык һәм ябык грунтта) | |
| | | дуңгызчылык | 5 |
| | | сарык, кәҗә үрчетү | |
| | | бөртекле һәм бөртекле-кузаклы, азык культуралар үстерү | |
| | | җимеш һәм җиләк культуралары үстерү | |
| | | бәрәңгечелек | |
| 2 | Авыл хуҗалыгы эшчәнлеге алып бару өчен җир кишәрлеге булу** | милектә, түләүсез файдалануда | 3 |
| | | грант акчаларын тотып бетергәннән соң кимендә 5 еллык озак вакытлы срокка арендада*** | 2 |
| 3 | Авыл хуҗалыгы эшчәнлеге алып бару өчен производство һәм склад биналары булу (ЛПХга карамаган) | милектә | 3 |
| | | арендада | 2 |
| 4 | Белем, эш стажы | югары яки урта – махсус авыл хуҗалыгы белеме турында документ булу | 3 |
| | | КФХ башлыгының авыл хуҗалыгында кимендә өч ел авыл хуҗалыгы белгечлеге буенча эш стажы булу | 3 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | булу | гариза бирүченең шәхси ярдәмче хуҗалыкны кимендә өч ел алып баруы яки уртак хуҗалыкта торуы | 2 |
| | | өстәмә авыл хуҗалыгы белеме курсларын тәмамлау турында документ булу | 1 |
| 5 | Бизнес-план акчалары каплану срогы | 1 – 3 елдан алып | 3 |
| | | 3 - 5 елга кадәр | 2 |
| | | 5 ел һәм аннан күбрәк | 1 |
| 6 | КФХ да авыл хуҗалыгы терлеге булу (шартлы баш саны)* | 10 һәм аннан күбрәк | 3 |
| | | 3 алып 9 кадәр | 2 |
| | | 1 алып 2 кадәр | 1 |
| 7 | Авыл хуҗалыгы кулланучылар коопреативларында КФХның әгъза булып торуы | кооператив әгъзасы | 2 |
| | | кооперативта әгъза булып тормау | 0 |
| КФХ башлыгының проектны уңышлы гамәлгә ашыруның төп факторларын белүенә бәя, (әңгәмәдән соң куела) | | | Максималь балл - 10 |

Искәрмә:

* 6 пунктта күрсәтелгән күрсәткечнең зурлыгын исәпләп чыгарганда терлек һәм кош-кортларны шартлы баш исәбенә күчергәндә түбәндәге коэффициентлар кулланыла: мөгезле эре терлек (олы) һәм ат – 1,0; мөгезле эре терлек (яшь) – 0,6; дуңгызлар - 0,3; сарыклар һәм кәҗәләр – 0,1; кош-корт - 0,02.

** Балл тиешле хокук гектарларының исәбе күбрәк булган саен югарырак була. Гектарларның исәбе бер үк булган очракта, бертөрле балл куела.

*** Грант акчаларын тотү срогы “Грант һәм үз акчаларын тоту графигы” 8 нче таблицада күрсәтелә.

5.10. Бәя куела торган һәр проект буенча йомгак балл чыгарыла, ул 5.9 пунктта күрсәтелгән критериеләр буенча гариза бирүче балларының суммасы буларак билгеләнә. Баллар бары тик тегелгән документлар буенча гына исәпләп чыгарыла. Конкурс комиссиясе утырышында тәкъдим ителгән документлар баллар суммасына кушылмый. Барлыгы 34 балл җыярга мөмкин. Конкурс комиссиясе уңай карар чыгарсын өчен 18 балл җыярга кирәк.

5.11. Беркетмә конкурс комиссиясе рәисе яки аның урынбасары, секретаре һәм утырышта катнашкан әгъзалары тарафыннан имзалана. Беркетмә имзаланганнан соң, Министрлык 5 көн эчендә конкурс сайлавы нәтиҗәләрен раслау турында боерык чыгара һәм аны Министрлыкның Татарстан Республикасы муниципаль районнарындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләренә җибәрә. Министрлык җиңүчеләр турында Министрлык боерыгы расланган көннән соң 3 эш көне эчендә

элемтә чаралары аша конкурсның җиңүчеләренә хәбәр итә, шулай ук конкурсның җиңүчеләре исемлеген Министрлыкның рәсми сайтына урнаштыра.

5.12. Грант алучы Министрлыкның рәсми сайтына җиңүчеләр исемлеге урнаштырылган көннән эш көннәре белән исәпләнә торган 10 конлек срок эчендә Министрлык белән 8 нче кушымтада каралган форма буенча грант бирү турында шартнамә (алга таба – шартнамә) төзи.

5.13. Әгәр грант откан фермерлар санының финанслауга бүлеп бирелгән суммага карата нисбәте кимрәк булса, Министрлык өстәмә конкурс игълан итә, ул әлеге Нигезләмәдә каралган тәртипкә нигезләнеп үткәрелә.

5.14. Грант алучы үз ихтыяры белән түбәндәге очракларда гариза бирә:

а) чыгымнар планы,

чыгымнар планындагы суммалар,

сатып алуларның исемнәре,

ферманың эшчәнлек юнәлеше,

грант акчаларының максатка ярашлы тотылуы турында хисап бирү срогы үзгәргәндә;

б) әлеге Нигезләмә кысаларында йөкләмәләрне үтәргә комачаулый торган шартлар турында.

Гаризаларны конкурс комиссиясенең чираттагы утырышында аның әгъзаларының тавыш бирү юлы белән башкарыла, ул Тавыш бирү кәгазендә һәм конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсендә теркәлә.

## 6. Грант бирү һәм аны кире кайтару тәртибе

6.1. Министрлык Татарстан Республикасы бюджет акчаларын төп бүлүче булып тора һәм акчаларны эш көннәрендә исәпләнә торган биш көнлек срокта Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган хосусый счетыннан Идарәләрнең Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең территориаль бүлекләрендә ачылган хосусый счетларына күчерә.

Акчаларны Идарәгә күчерү өчен нигез итеп Татарстан Республикасы муниципаль районына бирелергә тиешле грантлар турындагы җыелма исәп-хисап белешмәлеге алына, анда 10 нчы кушымтада бирелгән форма буенча грант алучылар һәм 9 нчы кушымтада күрсәтелгән форма буенча шартнамә һәм чыгымнар планы күрсәтелә.

6.2. Министрлык җыелма исәп-хисап белешмәлеген, шартнамәне һәм чыгымнар планын, аларның керүенә карап, махсус журналда терки, ул номерлана, тегелә һәм аңа Министрлык мөһере сугыла. Теркәү язмасы теркәү номерын, документларны кабул итү датасын һәм конкурс комиссиясе нәтиҗәләре буенча грант суммасын үз эченә ала.

6.3. Министрлык документлар теркәлгән көннән соң биш эш көне эчендә аңа кергән документларны тикшерә һәм грант алучы тарафыннан 6.2. пунктына ярашлы рәвештә тапшырылган чыгымнар планын, исәп-хисап белешмәлеген һәм шартнамәне имзалый.

6.4. Гариза бирүчегә грант бирүдән түбәндәге очракларда баш тартыла:

6.2. пунктында каралган документларның тулы пакеты тапшырылмаган булса;

6.2. пунктына ярашлы рәвештә тапшырылган документларда күрсәтелгән белешмәләрнең, исәп-хисапларның факттагы белешмәләргә, исәп-хисапларга туры килмәве ачыкланса.

6.5. Министрлык, Идарәләрнең Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең территориаль бүлекләрендә ачылган хосусый счетларына грант күчерү өчен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментына түбәндәгеләрне тапшыра:

а) конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсен раслау турында Министрлык боерыгын;

б) 6.2. пунктында күрсәтелгән һәм 6.3. пункты нигезендә имзаланган җыелма исәп-хисап белешмәлеге һәм шартнамә күчермәсен.

6.6. Идарә грантларны Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең территориаль бүлекләрендә ачылган КФХ хосусый счетларына КФХ башлыгы Идарәгә түбәндәге документларны тапшырган көннән соң 5 эш көненнән дә соңга калмыйча:

чыгымнар планында күрсәтелгән сатып алуларның һәр исеме бәясенең кимендә 40 процентын үз акчалары һәм (яки) кредит акчалары исәбеннән түләнүен раслый торган документларның 2 нче кушымтада каралган форма буенча, күрсәтелгән документларның күчермәләрен беркетеп, җыелма реестрны;

максат чыгымнарын түләүгә түләү йөкләмләрен, КФХ ның максат чыгымнары буенча йөкләмләре барлыкка килүгә нигез булган шартнамәләрне, аларда эш башкаручының (подрядчының, товар китерүченең) тулы исеме һәм товарның (хезмәт күрсәтүнең) исеме, чыгымнар планында каралган грант чикләрендәге суммага аларның саны (күләме).

6.7. Законнар нигезендә Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары КФХ максатларының, шартларының һәм грантлар бирү тәртибенең үтәлешен тикшереп тора.

6.8. Грант алучылар, "Грант күләме һәм бирү шартлары" дигән 2 бүлектә күрсәтелгән грант алу шартларын бозган очракта, законнар нигезендә җавап тоталар.

6.9. Грант бирү федераль бюджеттан һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслау лимитларын исәпкә алып башкарыла. Грант алуга конкурс сайлавын үткән гаризаларны канәгатьләндерү өчен быелгы елда бюджет акчалары җитәрлек булмаса, аларны финанслау әлеге Нигезләмәгә ярашлы рәвештә максималь баллар саны буенча чират тәртибендә гамәлгә ашырылачак.

6.10. Бирелгән грантлар, аларны бирүнең әлеге Нигезләмәдә һәм шартнамәдә каралган тәртибе һәм шартлары бозылу, конкурска дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшырылу, хисаплар тапшырылмау, максатчан билгеләнеше буенча файдаланылмау фактлары ачыкланган очракта, шулай ук грантлар бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешмәгән, максат күрсәткечләре бозылган очракта, Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән башлап 60 көн эчендә бюджет

законнары нигезендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

6.11. Шартнамәдә каралган очракларда, 18 ай дәвамында файдаланылмый калган грант акчалары КФХ тарафыннан грант файдалануның күрсәтелгән срогы беткәннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты керемена кире кайтарылырга тиеш.

6.12. Әлеге Нигезләмәнең 6.10 һәм 6.11 пунктларында күрсәтелгән акчаларны Татарстан Республикасы бюджеты керемена үз ихтыяры белән кайтарудан баш тартылган очракта, алар законнар нигезендә мәҗбүри рәвештә кире кайтарылырга тиеш.

2017 елның __ мартындагы ___/2-пр номерлы
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек
министрлыгы боерыгы белән расланган
Нигезләмәгә
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы
һәм азык-төлек министры урынбасары –
конкурс комиссиясе рәисе
Р.Р. Хәбиповка

___________________________________

___________________________________

(КФХ башлыгы Ф.И.А.и., яшәү урыны
адресы)

**“2017 – 2020 елларга Татарстан Республикасында эш башлаучы фермерларга ярдәм” ведомство программасында катнашучыларны конкурс нигезендә сайлап алуда катнашуга**
**гариза**

Мин, ___________________________________________________________

___________________________________________________________________

(гариза бирүченең тулы рәсми исеме)

мине “2017 – 2020 елларга Татарстан Республикасында эш башлаучы фермерларга ярдәм” ведомство программасында (алга таба – Программа) катнашучыларны конкурс нигезендә сайлап алуда катнашучылар составына кертүегезне сорыйм.

Моның белән мин түбәндәгеләрне раслыйм:

1. КФХ башлыгы булып эшләү урыны минем хезмәт эшчәнлегенең берданбер урыны булып тора, һәм мин, әлеге КФХ нан тыш, коммерция оешмасының гамәлгә куючысы (анда катнашучы) булып тормыйм.

2. КФХ карата үзгәртеп кору, юкка чыгару, банкротлык процедуралары үткәрелми һәм хуҗалык эшчәнлеген башкарырга чикләүләр юк;

3. КФХ Конкурс уздыру турында нигезләмәдә күрсәтелгән максатларга башка норматив хокукый актлар, муниципаль хокукый актлар нигезендә Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетыннан акча алучы булып тормый;

4. КФХ ның Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетына шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән субсидияләрне, бюджет инветицияләрен кайтару буенча вакыты узган бурычлары юк;

5. КФХ ның Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына Россия Федерациясе законнары нигезендә түләү срогы җиткән салымнар, җыемнар һәм башка түләү йөкләмәләре юк.

